**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2015 ел, 8 май

№ 332

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре турындагы Татарстан Республикасы бердәм мәгълүматлар банкын формалаштыру хакында» 2010 ел, 22 апрель, 294 нче карары белән расланган Социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре турындагы Татарстан Республикасы бердәм мәгълүматлар банкын формалаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре турындагы Татарстан Республикасы бердәм мәгълүматлар банкын формалаштыру хакында» 2010 ел, 22 апрель, 294 нче карары белән расланган Социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре турындагы Татарстан Республикасы бердәм мәгълүматлар банкын формалаштыру тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктында «Нигезләмә» сүзен «Тәртип» сүзенә алмаштырырга;

4.4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«республика дәрәҗәсендә – «Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә республика мәгълүмат-методика үзәге» дәүләт казна учреждениесе базасында Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан.»;

4.4 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бердәм мәгълүматлар банкы «Татарстан Республикасында социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләр һәм балигъ булмаганнар исәбе һәм мониторингы» мәгълүмат системасы ярдәмендә формалаша һәм социаль куркыныч хәлдә калган яңадан билгеле булган балигъ булмаганнар вә аларның гаиләләре турында мәгълүмат

килгәндә, алар турында, үткәрелә торган тернәкләндерү чаралары һәм аларның нәтиҗәләре турында мәгълүматлар үзгәргәндә тулылана.»;

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3 Мәгълүмат системасына керү әлеге Тәртипнең 4.1 пунктында күрсәтелгән бердәм мәгълүматлар банкын формалаштыру һәм куллану буенча катнашучыларның җаваплы вазыйфаи затлары тарафыннан шәхси теркәү мәгълүматлары нигезендә (пароль һәм логин) гамәлгә ашырыла.

Шәхси теркәү мәгълүматлары «Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә республика мәгълүмат-методика үзәге» дәүләт казна учреждениесе тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләренең язмача гаризалары нигезендә бирелә.»;

Тәртипкә кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләр һәм балигъ булмаганнар исәбе һәм мониторингы» мәгълүмат системасын файдаланып, социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре турындагы Татарстан Республикасы бердәм мәгълүматлар банкын формалаштыру регламенты»

| Үтәүчеләр | Башкарылган операция һәм тапшырылган мәгълүматның кыскача тасвирламасы | Мәгълүмат формасы | Башкару сроклары | Мәгълүматны алучы | Агымдагы контрольне гамәлгә ашыру |
|---|---|---|---|---|---|
| Профилактикалау системасының территориаль органнары һәм учреждениеләре | Мәгълүмат системасында социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганга һәм аның гаиләсенә сигнал картасын формалаштыра | электрон форма | ачыкланган саен | гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү үзәге/бүлеге | МСТК рәисе |
| Гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү үзәге/ бүлеге | Сигнал картасын карап тикшерә һәм профилактикалау системасы субъектлары белгечләре арасынан тикшерү төркеменә социаль куркыныч хәленә бәйле мәгълүмат системасында сигнал җибәрә | электрон форма | Эш көннәрендә Мәскәү вакыты буенча 9.00 сәгатьтән алып 17.00 сәгатькә кадәр, ял көннәре һәм бәйрәм көннәреннән гайре, бер сәгать эчендә | тикшерү төркеме | МСТК рәисе |
| МСТК | Тикшерү акты нигезендә балигъ булмаганны һәм аның гаиләсен ведомствоара патронатка кую кирәклеге турында карар кабул итә, патронатның төрен билгели; профилактикалау системасы субъектлары вәкилләре арасыннан эшче төркем составын формалаштыра, ИТП проектын эшли, аны тормышка ашыру срокларын билгели; ББЭһХЯКга социаль | документ/ электрон форма | сигнал картасы кергәннән соң 15 көн эчендә | ББЭһХЯК | ББЭһХЯК рәисе |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганны һәм аның гаиләсен ведомствоара патронатка кую турында үтенеч юллый | | | | |
| | Әгәр балигъ булмаган һәм аның гаиләсе социаль куркыныч хәлдә булмаса, гаиләгә авыр тормыш хәлен ерып чыгарга булышу өчен үтенеч профилактикалау системасы субъектының берсенә җибәрелә | документ | сигнал картасы кергәннән соң 15 көн эчендә | профилакти-к алау системасы субъектлары | профилакти-калау системасы-ның территори-аль органы яки учреждение-се җитәкчесе |
| ББЭһХЯК | Балигъ булмаганны һәм аның гаиләсен ведомствоара патронатка кую турында карар чыгара, эшче төркемне һәм ИТП раслый яисә ведомствоара патронат оештыру кирәклеге турында МСТК карарын кире кага | документ/ электрон форма | МСТК утырышын үткәргәннән соң 15 көн эчендә | МСТК | ББЭһХЯК |
| Эшче төркем | ИТП нигезендә чаралар үткәрәләр һәм мәгълүмат системасы ярдәмендә башкарылган эш турында мәгълүмат кертәләр | электрон форма | ведомствоара социаль патронат чорында | МСТК | МСТК |
| МСТК | МСТК кабат үткәрелгән утырышлары кысаларында ИТП тормышка ашыру мониторингын, ИТП чараларына төзәтмәләр кертүне башкара, тернәкләндерү эше тәмамлану турында ББЭһХЯК тәкъдимнәр юллый | документ/ электрон форма | план буенча: патронатның һәр этабында<br><br>оператив: хәл буенча | ББЭһХЯК | ББЭһХЯК рәисе |
| ББЭһХЯК | МСТК эшчәнлеген координацияләүне һәм контрольне гамәлгә ашыра; социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләсенә ведомствоара муниципаль социаль патронат системасының эшләвен тәэмин итә | электрон форма | даими | ББЭһХЯРК | ББЭһХЯРК |
| ББЭһХЯК | Ведомствоара исәптән төшерү турында карар чыгара (уңай нәтиҗәләр белән яки нәтиҗәләргә ирешмичә) | документ/ электрон форма | МСТК утырышыннан соң 15 көн эчендә | МСТК | ББЭһХЯРК |
| Гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм үзәге/бүлеге | Муниципаль дәрәҗәдә бердәм мәгълүматлар банкын формалаштыру турында мәгълүмат әзерли | электрон форма | ай саен/ квартал саен (хисап чорыннан соң килүче айның 23 көненә кадәр) | ББЭһХЯК РММҮ | ББЭһХЯК |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| РММҮ | Мәгълүмат системасында статистик хисаплылыкны координацияләүне; мәгълүмат системасында кулланучыларны теркәү-не һәм исәп язуларына үзгәрешләр кертүне га-мәлгә ашыра | документ/ электрон форма | даими | ТР ХХЭТИhСЯМ ББЭhХЯК | ТР ХХЭТИhСЯ М |
| ТР МhЭМ | Мәгълүмат системасын техник яктан озатып баруны; программалы продуктны модификация-ләүне тәэмин итә | электрон форма | даими | ББЭhХЯК | МИС РТ |

Кулланылган кыскартулар исемлеге:

Профилактикалау системасының территориаль органнары һәм учреждениеләре – бердәм мәгълүматлар банкын формалаштыруда катнашучылар;

Гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм үзәге/бүлеге – Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы ведомствосындагы Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларында халыкка социаль ярдәм күрсәтү комплекслы үзәкләренең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәмнең территориаль үзәкләре, гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм бүлекләре;

ББЭhХЯРК – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе;

ББЭhХЯК – Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларында Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия;

ИТП – социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганны һәм аның гаиләсен индивидуаль тернәкләндерү программасы;

МСТК – Муниципаль социаль-тернәкләндерү консилиумы;

Эшче төркем – гаиләне һәм ИТПны тормышка ашыруны күз астында тоткан төрле ведомстволар белгечләре төркеме;

РММҮ – Социаль хезмәт күрсәтү тармагында республика мәгълүмат-методика үзәге;

ТР ХЭТИhСЯМ - Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;

ТР МhЭМ – Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\332.doc